ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2020 г. Заинск №249

**«Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексын гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаны расларга (кушымта).
2. «Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында» 2017 елның 24 маендагы 936 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныrга
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А. Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма комитет
җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

А.М. Куликова
(85558)7-08-18

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитының
15.06. 2020 ел
249__ номерлы карарына
кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШКАН КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРДА ГОМУМИ МИЛЕКНЕ КАПИТАЛЬ РЕМОНТЛАУ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ АДРЕСЛЫ ПРОГРАММА**

| | |
|---|---|
| | Программаның паспорты |
| Программаның исеме | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү турында карар кабул итүгә нигез | Россия Федерациясе Торак кодексы; «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Закон) |
| Программаны әзерләүче | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын яхшырту;<br>Гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | Халык белән актив агитация-аңлату эше алып бару;<br>Башкарма Программаны сайлап алуның ачык һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;<br>Использование эффективных технических решений и комплексности Капиталь ремонт үткәргәндә чыдамлы материаллар һәм ресурсларны саклый торган технологияләр кулланып, нәтиҗәле техник чишелешләр һәм комплекслылыктан файдалану |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2014-2043 еллар |
| Программаны тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр | Торак фондын Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерү (шул исәптән халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, техник җайга салу, кулланучылар хокукларын яклау турында) |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты программаны тормышка ашыруны контрольдә тота |

## Характеристика проблемы

Программаны кабул итүнең актуальлеге кайбер социаль-икътисадый факторларга бәйле. Социаль факторлар торак хезмәтләренең түбән сыйфатлы булуы һәм торак фонды объектларының потенциаль авария хәлендә булуы, икътисадый фактор - аны тотуга югары эксплуатация чыгымнары белән бәйле.

Аталган проблемаларны хәл итүдә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында «Россия гражданнарына - арзанлы һәм уңайлы торак» милли проекты өстенлекле юнәлеше булып тора һәм әлеге Программаны гамәлгә ашыру срокларын оештыру, җитештерү, социаль-икътисадый һәм башка чаралар комплексын үткәрүнең һәм аны үтәүчеләрнең эшчәнлеген координацияләүнең дәүләт заказчысы тарафыннан программа методлары белән генә хәл ителергә мөмкин.

## Программаны үтәүнең төп максатлары, бурычлары, гамәлгә ашыру сроклары һәм планлаштырыла торган күрсәткечләре

Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын яхшырту;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итү.

Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

Программаны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;

капиталь ремонт үткәргәндә чыдамлы материаллар һәм ресурсларны саклый торган технологияләр кулланып, нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны тәэмин итү.

Әлеге программа 2014-2043 елларда гамәлгә ашырылачак.

Программаны гамәлгә ашыру 219 күпфатирлы йортта яшәүче гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге Программа үтәлешенең планлаштырылган күрсәткечләре аңа кушымтада бирелгән.

## Күпфатирлы йортларны Программага кертү шартлары

Программага Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар кертелә, моңа Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлар керми.

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүнең чираты Программада законда күрсәтелгән критерийлар нигезендә билгеләнә.

## Программа чаралары

Программаның төп чаралары:

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча түбәндәге хезмәтләр һәм (яисә) эшләрне башкару:

йорт эчендәге инженерлык системаларын электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, юынтык суларны чыгару, шул исәптән торак урыннардагы җылыту элементларын ремонтлау яисә алмаштыру, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында урнашкан механик, электр, санитар-техник җиһазларны;

эксплуатацияләү өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазларын ремонтлау яисә алмаштыру, лифт шахталарын ремонтлау, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазлау;

түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляцияләнми торган түбәне вентиляцияләнә торганга үзгәртү, түбәгә чыгу юлларын көйләү;

күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау;

фасадны җылыту һәм ремонтлау, халыкның аз мобильле төркемнәре өчен күпфатирлы йортта гомуми милектән файдалана алуны тәэмин итү максатларында подъездларны пандуслар һәм баскычларны ике яктан да култыксалар белән җиһазлау;

коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслардан файдалануны исәпкә алуның коллектив (гомумйорт) приборларын (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) һәм әлеге ресурслардан файдаланганда идарә итү һәм җайга салу узелларын урнаштыру яисә алмаштыру;

күпфатирлы йорт нигезен ремонтлау; күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау;

күпфатирлы йортта энергетика тикшерүе үткәрү; проект документациясенә дәүләт экспертизасын эшләү һәм уздыру (проект документларын әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булган очракта);

төзелеш контролен гамәлгә ашыру;

күпфатирлы йортның янгыннан саклау системасын ремонтлау; күпфатирлы йортларның техник инвентарьлаштыру эшләрен башкару һәм техник паспортлар әзерләү;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәт составына кермәгән, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәт составында капиталь ремонт эшләрен башкарганда ремонтлана торган (алмаштырыла торган) конструкцияләр һәм инженерлык системалары технологик һәм конструктив үзенчәлекләре аркасында демонтажланган яисә җимерелгән мөлкәт өлешләрен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү эшләрен башкару;

2014 елның 1 июненә кадәр чорда куелган күпфатирлы йортлардагы коммуналь ресурсларны куллануны исәпкә алуның коллектив (гомумйорт) приборларын урнаштыру (алмаштыру);

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр яхшыртылган эксплуатация характеристикаларына ия чыдамлы һәм экономияле материаллар кулланып гамәлгә ашырыла.

2. Программаны мәгълүмати тәэмин итү, уздырыла торган процедураларның ачыклыгын тәэмин итү түбәндәге юллар белән башкарыла:

Программаны гамәлгә ашыру барышын район массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртып тору (вакытлы басмаларда - газеталарда, журналларда, шул исәптән электроннарда; радио- һәм телеканалларда);

торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру һәм капиталь ремонт үткәрү мәсьәләләрен яктырту өчен махсус теле- һәм радиопрограммалар булдыру;

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтын актуаль хәлдә тоту;

торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру һәм капиталь ремонт уздыру мәсьәләләре буенча тематик методик һәм белешмә материаллар чыгару һәм тарату;

торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак төзелеше кооперативлары, идарәче оешмалар тарафыннан гражданнарга күпфатирлы йортта капиталь ремонт ясау эшләрен башкаруның планлаштырыла торган сроклары турында мәгълүмат җиткерү (Программага кертелгән күпфатирлы йортның һәр подъездында яисә шундый йорт урнашкан җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан белдерүләр такталарында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтларында (булган очракта) тиешле мәгълүматны урнаштыру).

## Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге Программаны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бер елга Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы (еллык) планнары (алга таба - Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнары) раслана.

Программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнарын әзерләү һәмраслау ел саен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана торган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча озак сроклы программаны тормышка ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

## Программага үзгәрешләр кертү тәртибе

Программа елына кимендә бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш.

Программаны актуальләштерү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Программага кертелгән күпфатирлы йортны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану;

Программага кертелгән күпфатирлы йорт урнашкан җир кишәрлеген законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу һәм шушы күпфатирлы йорттагы һәр торак урынны тартып алу;

яңа күпфатирлы йортларны файдалануга кертү;

Программага кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеген үзгәртү;

Программага кертелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын үзгәртү;

Программага үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә торган башка

нигезләр. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча билгеләнгән срокны соңрак чорга күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төрләре исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләрне капиталь ремонтлау буенча озак сроклы программага кертү законнарда билгеләнгән тәртиптә милекчеләренең гомуми җыелышының тиешле карары булганда гамәлгә ашырыла.